**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТАКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17,с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

_________                                        № ______

**2026 елга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында**

2025 елның 30 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы «2026 елга 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы белән, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елга гомуми белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http//www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.М.Шакировага йөкләргә.

Җитәкче                                        И.Ш. Бариев

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
______________ №____
карарына кушымта

1. Гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары

| Гомуми белем баскычы | Класс төре | Елына бер укучыга норматив, сумнарда[1] |
|---|---|---|
| | | авыл җирлеге |
| Башлангыч гомуми белем | Гомуми белем бирү класслары | 67294 |
| | Экстернат | 22583 |
| | Өйдә укыту | 278826 |
| | Аз комплектлы гомуми белем бирү оешмасы | 739792 |
| | Озайтылган көн төркеме | 14180 |
| | Башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен өстәмә гомуми белем бирү программалары | 3815 |
| Төп гомуми белем | Гомуми белем бирү класслары | 94020 |
| | Экстернат | 35922 |
| | Өйдә укыту | 366637 |
| | Аз комплектлы гомуми белем бирү оешмасы | 1179913 |
| | Озайтылган көн төркеме | 9011 |
| | Башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен өстәмә гомуми белем бирү программалары | 4411 |
| Урта гомуми белем | Гомуми белем бирү класслары | 104053 |
| | Экстернат | 39823 |
| | Өйдә укыту | 442476 |
| | Аз комплектлы гомуми белем бирү оешмасы | 1327691 |
| | Башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен өстәмә гомуми белем бирү программалары | 5426 |

[1]. Аз комплектлы гомуми белем бирү оешмалары өчен елына бер сыйныф-комплектка норматив кулланыла.

2. Гомуми белем бирү оешмаларында дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар

| Гомуми белем баскычы | Елына бер укучыга норматив, сумнарда |
|---|---|
| Башлангыч гомуми белем | 1358 |
| Төп гомуми белем | 2071 |
| Урта гомуми белем | 2589 |